**Тукай муниципаль районы Сәмәкәй авыл җирлеге Оргыды авылы**
**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

«28» октябрь, 2023 ел № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Оргыды авылы гражданнар җыены

**КАРАР БИРДЕ:**

1. 2024 елда яшәү урыны буенча Сәмәкәй авыл җирлеге Оргыды авылы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә 500 (биш йөз) сум күләмендә бер тапкыр түләү кертергә һәм I, II төркем инвалидлары һәм Бөек Ватан сугышы ветераннары, ялгыз яшәүче өлкән яшьтәге гражданнар һәм көндезге формада укучы студентлар, күп балалы гаиләләр өчен бер тапкыр түләү күләмен киметергә һәм аны әлеге категория гражданнар өчен 250 (ике йөз илле) сум күләмендә билгеләргә, әлеге сумманы түбәндәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә:

- чокыр ремонтлау, юллар төзү, вак таш сатып алу, махсус техника хезмәтләре;

2. Тукай муниципаль районы Сәмәкәй авыл җирлеге Оргыды авылы гражданнар җыены нәтиҗәсен авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырып, халыкка җиткерергә.

3. Тукай муниципаль районы Сәмәкәй авыл җирлеге Оргыды авылы гражданнар җыены нәтиҗәсен Тукай муниципаль районының рәсми сайтында «авыл җирлекләре» бүлегендә, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче
Оргыды авыл җирлеге Башлыгы И.М.Усманов

Совет
СЕМЕКЕЕВСКОГО
сельского поселения